ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27 12 2021 г. № 1054

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучыларга торак урыннардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучыларга торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында» 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы боерыгы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучыларга торак урыннардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәреш кертергә:

карарга кушымтаның 1 пунктындагы тугызынчы абзацында «0,088» санын «0,071» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама

муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Х.Муллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МКУ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ *
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874